КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 октябрь г.Казань № 961

2019 елга Татарстан Республикасын газлаштыру
буенча чаралар планын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын формалаштыру тәртибен раслау турында” 2018 ел, 22 август, 693 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2019 елга Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Җаваплылыгы чикләнгән “Газпром трансгаз Казань” җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәтләре өчен тарифларга махсус өстәмә түләүләр кулланудан алынган акча хисабыннан финанслана торган 2019 елга Татарстан Республикасын газлаштыру программасын раслау турында” 2018 ел, 19 сентябрь, 803 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. “Җаваплылыгы чикләнгән “Газпром трансгаз Казань” җәмгыятенә 2020 елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгына 2019 елга Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын үтәү турында хисап кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин